**“Мин татарча сөйләшәм” акциясе турында мәгълүмат**

**2016-2017 нче уку елы**

Мәктәбебездә 21 нче февраль көнне Халыкара туган тел көне билгеләп үтелде. Татар теле һәм әдәбияты укытучылары тарафыннан төрле чаралар үткәрелде. Бу чараларда укучыларыбыз бик теләп катнаштылар. Шигырь, хикәя кичәләре, рәсем конкурслары гөрләп узды. Туган тел көненә багышланган кичәләр ата-аналар катнашында дәвам итте. Туган тел көне үтеп тә өлгермәде ана теле укытучылары Республика күләмендә уздырылучы **“Мин татарча сөйләшәм”** акциясенә әзерлекне башлап та җибәрделәр. Мәктәп күләмендә бу чарага багышланган бик күп ачык дәресләр, сыйныф сәгатьләре, кызыклы чаралар узды. Укучылар буклетлар, логотиплар ясадылар, класстан класска кереп, волонтерлар башлангыч сыйныф укучылары белән әңгәмәләр уздырдылар. ”Мөстәкыйль балалар»отряды дисскусияләр уздырды. Акция мәктәп диварларына гына сыймыйча, шәһәр урамына таралды. Укучылар үзләре ясаган буклетларны зур сәүдә йортларында, узәктә, автовокзалда шәһәр халкына тараттылар, видео конференция уздырып, татар телендә башка милләт вәкилләре белән аралаштылар. Акциядән ата-аналар да читтә калмады. Ата-аналар җыелышында **“Мин татарча сөйләшәм”** акциясе турында сөйләнде. Ата-аналар балалар тараткан логотипларны, буклетларны үзләренең эш урыннарында тараттылар, хезмәттәшләренә татар теленең матурлыгы, яңгырашы турында сөйләделәр, татар телен өйрәнергә өндәделәр. Каникулдан соң балалар акция турында фикер алышу һәм телебезне тагын куркәмрәк итеп югарылыкка күтәрү өчен түгәрәк өстәл артына җыелачаклар. Бу исәптән мәктәпнең татар теле һәм әдәбияты укытучыларының планнары бик зурдан.

Л.Р.Даутова, татар теле һәм әдәбияты укытучысыларының методик берләшмә җитәкчесе

.